**Татарстан Республикасы**

**Арча муниципаль районы**
**Арча муниципаль берәмлеге**
**Арча шәһәре**
**башкарма комитеты**

**422000, ТР, Арча ш., мәйдан Советы, 27**

**тел. 3-15-25, 3-12-35**

**Муниципальное образование**

**город Арск**

**Арского муниципального района**
**Республики Татарстан**

**исполнительный комитет**
**города Арск**
**422000, РТ, г.Арск, площадь Советская,272727**

**тел. 3-15-25, 3-12-35**

# КАРАР

**« 6 » июль 2020 ел** **№ 57**

**«Татарстан Республикасының иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе" республика конкурсы җиңүчеләренә грантлар бирү өчен Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Арча шәһәре бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү Тәртибен раслау турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 142 статьясы нигезендә Арча шәһәре Башкарма комитеты карар бирә:

1. 1 нче кушымта итеп бирелгән «Татарстан Республикасының иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсы җиңүчеләренә грантлар бирү өчен Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Арча шәһәре бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү Тәртибен расларга.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Арча шәһәре Советының баш белгече Э.Р. Сабировага йөкләргә (килешү буенча).

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru) һәм «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы рәсми сайтында халыкка җиткерергә (http://arsk/tatarstan.ru).

Арча шәһәре башкарма
комитеты җитәкчесе Р.Ф. Касыймов

Арча шәһәре башкарма
комитетының 2020 елның 6
июлендәге 57 номерлы
карарына кушымта

“Татарстан Республикасының иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе" республика конкурсында җиңүчеләргә грантлар бирү өчен финанслау чыганагы Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар булган Арча муниципаль районы Арча шәһәре бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү
Тәртибе

1. Әлеге Тәртиптә «Татарстан Республикасының иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсында җиңүчеләргә грантлар бирү өчен Арча муниципаль районы Арча шәһәре бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар (алга таба – башка бюджетара трансфертлар) бирү максатларын, тәртибен һәм шартларын билгели.

2. Башка бюджетара трансфертлар Арча муниципаль районы “Арча шәһәре” муниципаль берәмлеге территориясендә теркәлгән Конкурс җиңүчеләренә һәм призерларына бирелә.

3. Башка бюджетара трансфертлар әлеге максатларга Арча муниципаль районы Арча шәһәр Советының тиешле финанс елына һәм план чорына Арча муниципаль районы “Арча шәһәре” муниципаль берәмлеге бюджеты турындагы карарында билгеләнгән бюджет ассигнованиеләре күләме чикләрендә бирелә.

4. Әлеге Тәртип нигезендә бирелә торган бюджет ассигнованиеләрен баш бүлүче булып Арча муниципаль районы “Арча шәһәре” муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты (алга таба – Башкарма комитет) тора.

5. Территориаль иҗтимагый үзидарәләргә башка бюджетара трансфертлар бирү шартлары:

«Татарстан Республикасының иң яхшы территориаль үзидарәсе" республика конкурсының конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсе булу;

Җирлекнең Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә теркәлгән территориаль иҗтимагый үзидарәләргә конкурста җиңүчеләргә һәм призерларга грантлар бирү буенча чыгым йөкләмәләрен билгели торган муниципаль хокукый акты булу.

6. Башка бюджетара трансфертларны кулланунын нәтиҗәлелеге күрсәткече-конкурста җиңүчеләргә һәм призерларга түләнгән грантлар саны.

7. Башка бюджетара трансфертлар Башкарма комитет һәм территориаль иҗтимагый үзидарә арасында төзелгән шартнамә нигезендә Башкарма комитет тарафыннан расланган формада бирелә (алга таба – Шартнамә).

8. Шартнамәдә карала:

башка бюджетара трансфертларның күләме, аларның максатчан билгеләнеше;

башка бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткечләре;

башка бюджетара трансфертлардан файдалану һәм башка бюджетара трансфертларны бирүнең нәтиҗәлелеге күрсәткечләренә ирешү турында хисап тапшыру сроклары һәм формалары;

башка бюджетара трансфертларны алучының башка бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәлелегенең билгеләнгән күрсәткеченә ирешмәү нәтиҗәләре;

Шартнамәдә каралган башка бюджетара трансфертлар алучы тарафыннан үтәүне контрольдә тотуны гамәлгә ашыру тәртибе;

Шартнамә шартларын бозган өчен якларның җаваплылыгы.

9. Башка бюджетара трансфертлар Башкарма комитет тарафыннан касса хезмәте күрсәтү өчен ачылган территориаль иҗтимагый үзидарәләр счетларына күчерелә.

10. Территориаль иҗтимагый үзидарә Башкарма комитетка башка бюджетара трансфертлардан файдалану һәм Шартнамәдә каралган срокларда һәм формада башка бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткечләренә ирешү турында хисап тапшыра.

11. Агымдагы финанс елының 1 гыйнварына кулланылмаган башка бюджетара трансфертлар, Россия Федерациясе Бюджет кодексы белән билгеләнгән таләпләр нигезендә, Арча муниципаль районы Арча шәһәре бюджеты керемендә кире кайтарылырга тиеш.

12. Территориаль иҗтимагый үзидарә һәм вазыйфаи затлар закон нигезендә тапшырыла торган хисап белешмәләренең дөреслеге һәм башка бюджетара трансфертларны бирү шартларын үтәү өчен җаваплы.

13. Башка бюджетара трансфертлар бирү шартлары бозылган очракта, әлеге акчалар Россия Федерациясе бюджет законнарында билгеләнгән тәртиптә Арча муниципаль районы Арча шәһәре бюджеты керемендә күчерелергә тиеш.

15. Әлеге Тәртип нигезендә бирелгән башка бюджетара трансфертларның максатчан кулланылышын закон нигезендә Арча муниципаль районы Арча шәһәре башкарма комитеты һәм «ТР Арча муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы» МКУ контрольдә тота.

Башка бюджетара трансфертлар
бирү Тәртибенә кушымта

“Татарстан Республикасының иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе"
республика конкурсында җиңүчеләргә грантлар бирү өчен финанслау чыганагы
Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар булган Арча
муниципаль районы Арча шәһәре бюджетыннан башка
бюджетара трансфертлар бирү
турында Шартнамә

«___»_________20___ел

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Арча шәһәре Башкарма комитеты, алга таба - «Башкарма комитет» дип аталучы ________________________ исеменнән Устав нигезендә эш итүче бер яктан һәм ______________________, алга таба «Башка бюджетара трансфертлар Алучы» дип аталучы икенче яктан, бергә «Яклар» дип аталачак, Арча муниципаль районы Арча шәһәре Башкарма комитетының 2020 елның 6 июлендәге “Татарстан Республикасының иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе" республика конкурсында җиңүчеләргә грантлар бирү өчен финанслау чыганагы Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар булган Арча муниципаль районы Арча шәһәре бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү Тәртибен раслау турында” 57 номерлы карары нигезендә, "Татарстан Республикасының иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе" республика конкурсында җиңүчеләргә грантлар бирү өчен әлеге шартнамәне төзеделәр:

1. Шартнамә предметы

1.1. Әлеге шартнамә предметы булып «Татарстан Республикасының иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсында җиңүчеләргә әлеге Шартнамәдә, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында һәм муниципаль хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә һәм шартларда грантлар бирүгә башка бюджетара трансфертлар бирү тора.

1.2. Башка бюджетара трансфертлар Арча шәһәре Советының «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегенең тиешле финанс елына бюджеты турында» карары үз көченә кергән көннән алып гамәлгә ашырыла, ул «Татарстан Республикасының иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсында җиңүчеләргә грантлар бирү өлешендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы бюджетыннан территориаль иҗтимагый үзидарәгә ярдәм итүгә башка бюджетара трансфертлар бирүне күздә тота.

## 2. Якларның хокуклары

2.1. Башкарма комитет хокуклы:

2.1.1. Башкарма комитет тарафыннан билгеләнгән тәртип нигезендә, башка бюджетара трансферт Алучының аларны алу шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүләрен тикшерергә.

2.2. Башка бюджетара трансферт Алучы хокуклы:

2.2.1. Башкарма комитеттан Шартнамә буенча башка бюджетара трансфертларны алу тәртибенә кагылышлы язма сорауларга язмача аңлатмалар алырга.

## 3. Якларның бурычлары

3.1. Башкарма комитет бурычлы:

3.1.1. Башка бюджетара трансфертларны әлеге Шартнамәдә каралган тәртиптә һәм шартларда күчерергә.

3.1.2. Башка бюджетара трансферт Алучының алу шартларын, максатларын һәм аларны алу тәртибен үтәүне тикшерергә.

3.1.3. Башка бюджетара трансферт Алучы тарафыннан Тәртиптә каралган башка бюджетара трансферт бирү шартларын бозганда, хокук бозу ачыкланган көннән соң 10 эш көне эчендә башка бюджетара трансферт Алучыга башка бюджетара трансфертларны кире кайтару турында язма рәвештә таләп җибәрергә.

3.2. Башка бюджетара трансферт Алучы бурычлы:

3.2.1. Башкарма комитетка башка бюджетара трансферттан файдалану һәм аларны бирү шартларының үтәлеше турында әлеге Шартнамәнең 2 нче кушымтасындагы форма буенча хисап бирергә.

3.2.2. Әлеге Шартнамә нигезендә алынган башка бюджетара трансфертның максатчан һәм нәтиҗәле кулланылышын тәэмин итәргә. Башка бюджетара трансферт Алучы Башкарма комитет һәм муниципаль финанс тикшерүе органы тарафыннан әлеге Шартнамәдә билгеләнгән тәртиптә башка бюджетара трансфертлар бирү шартларының, максатларының һәм тәртибенең үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыруга риза.

3.2.3. Тәртип һәм Шартнамәнең 3.1.3 пункты нигезендә башка бюджетара трансфертны (яисә бер өлешен) Алучы кире кайтару турында язма таләп алган көннән җиде эш көне эчендә кире кайтарырга.

## 4. Шартнамә буенча исәп-хисап

4.1. Әлеге Шартнамә буенча башка бюджетара трансферт суммасы «Татарстан Республикасының иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсының конкурс комиссиясе карары нигезендә________________ сум күләмендә билгеләнгән.

## 5. Якларның җаваплылыгы

5.1. Яклар әлеге Шартнамә буенча йөкләмәләрне үтәмәгән һәм (яки) тиешенчә үтәмәгән өчен Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары нормалары нигезендә җаваплы.

Тәртиптә каралган башка бюджетара трансфертларны бирү шартлары башка бюджетара трансферт Алучы тарафыннан бозылганда, Башкарма комитет закон бозу ачыкланган көннән соң 10 эш көне эчендә башка бюджетара трансферт Алучыга башка бюджетара трансфертны кире кайтару турында язмача таләп җибәрә. Башка бюджетара трансфертлар Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Арча шәһәре бюджетына башка бюджетара трансферт Алучы тарафыннан кире кайтару турында язма таләп алынганнан соң җиде эш көне эчендә кире кайтарылырга тиеш.

5.2. Билгеләнгән срокта башка бюджетара трансферт кире кайтарылмаган очракта, түләтү гамәлдәге законнарда каралган тәртиптә башкарыла.

## 6. Контрольлек итү

6.1. Башка бюджетара трансферт Алучы Башкарма комитетка башка бюджетара трансферт бирү тәртибен, максатларын һәм шартларын үтәүне тикшереп торуны гамәлгә ашыру өчен соратып алына торган документлар һәм мәгълүматны әлеге таләп алынган көннән алып биш эш көне эчендә тапшыра.

6.2. Башка бюджетара трансферт акчаларының максатчан кулланылышын контрольдә тоту Шартнамәнең 3.2.1. пунктында күрсәтелгән хисаплар нигезендә Башкарма комитет тарафыннан гамәлгә ашырыла.

## 7. Шартнамәнең гамәлдә булу вакыты

7.1. Әлеге Шартнамә Яклар тарафыннан имзаланган вакыттан башлап үз көченә керә һәм Якларның үз йөкләмәләрен тулысынча үтәүләренә кадәр гамәлдә була.

7.2. Әлеге Шартнамә Яклар килешүе яисә граждан законнарында каралган нигезләр буенча суд карары нигезендә вакытыннан алда өзелергә мөмкин.

## 8. Махсус шартлар

8.1. Әлеге Шартнамәгә кертелгән барлык үзгәрешләр һәм өстәмәләр язма рәвештә өстәмә килешүләр белән рәсмиләштерелә һәм ике як та кул куя.

8.2. Әлеге Шартнамә ике нөсхәдә төзелде, алар бер үк юридик көчкә ия.

## 9. Якларның юридик адреслары, реквизитлары һәм имзалары

| Башкарма комите | Башка бюджетара трансфертлар Алучы |
| --- | --- |

Шартнамәгә
1 нче кушымта

(Форма)

Арча шәһәре Башкарма комитеты
җитәкчесе

____________________________

**Хисап**

______________________________________________________________________

*(территориаль иҗтимагый үзидарә атамасы)*
башка бюджетара трансферттан файдалану турында

«Татарстан Республикасының иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе" республика конкурсы җиңүчеләренә грантлар бирү өчен Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Арча шәһәре бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү Тәртибен раслау турында 2020 елның 6 июлендәге 57 номерлы карары нигезендә бирелгән башка бюджетара трансфертларның түбәндәгечә тотылышын раслыйм.

| Вакыты, урыны күрсәтелгән эшләр, күрсәтелгән хезмәтләр исемлеге | Катнашучылар саны, кеше | Чаралар үтәлешен раслый торган документлар исеме һәм реквизитлары | Барлыгы, шул исәптән бюджеттан тыш акчалар, сум |
|---|---|---|---|
| | | | |
| | | | барлыгы |

Хисапка әлеге хисаптагы мәгълүматларны раслый торган тиешенчә расланган документлар күчермәләре һәм фотоматериаллар теркәлә.

ТИҮ рәисе «_______________»

Ф. и. а.и.__________________________ имза_____________________

Дата_______________________